СИШӘМБЕ
12 ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 9 (6731)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ

КЫШКЫ АГРОТЕХНИКА ЧАРАЛАРЫН ҮТКӘРҮГӘ ҖИТДИ ИГЪТИБАР

Колхоз строе авыл хуҗалыгын нигезеннән үзгәртте. Иген уңышын күтәрү, терлекчелекне үстерү һәм авыл хуҗалыгының барлык башка тармакларын алга җибәрү өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылды. Шул мөмкинлекләрдән файдалану нигезендә соңгы елларда безнең социалистик авыл хуҗалыгыбыз ашлыкны, итне, сөт һәм майны, яшелчәне, промышленность өчен чималны элеккегә чагыштырганда берничә тапкыр артыграк җитештерә башлады.

Бөек коммунистлар партиясе тарафыннан һәм турыдан-туры иптәш Сталин тарафыннан аталарча кайгыртучанлык күрсәтелү нәтиҗәсендә, миллионнарча крестьяннар колхозда чын намус белән эшләп культуралы, таза тормышлы кешеләргә әйләнделәр.

Партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан күрсәтелгән бу кайгыртучанлыкны Совет иле крестьяннары бер вакытта да онытмаячаклар һәм онытмыйлар. Бу, барыннан да элек, Ватан интересларын саклауда, илебезнең барлык хезмәт ияләре белән берлектә, крестьяннарның да актив катнашуларында ачык гәүдәләнә. Танклар һәм самолетлар төзелешенә акча туплау буенча киң җәелеп киткән һәм хәзердә дә уңышлы дәвам итә торган патриотик хәрәкәт, безнең крестьяннарыбызның чыннан да ил интересларын саклауда бер нәрсәләрен дә кызганмауларын һәм кызганмаячакларын аеруча ачык күрсәтте. Бу гүзәл хәрәкәтне дәвам иттерергә, дошманны тәмам тар-мар итеп бетергәнчегә кадәр дәвам иттерергә һәм бу эштә һәрбер колхозчының һәм һәрбер колхозчы хатын-кызның катнашуына бөтен мөмкинлекләрне тудырырга һәм аңа җитәкчелек итәргә кирәк.

Ләкин шул ук вакытта Кызыл Армиябезгә икенче төрле булышлыкны да истән чыгармаска кирәк. Нинди генә эш тармагы булмасын, аны башкарганда иң беренче чиратта ил интереслары, Кызыл Армиябез интереслары торырга тиеш. Сүз, язгы чәчүгә әзерлек һәм аның иң әһәмиятле буыннарыннан булган кышкы агротехника чараларын үткәрү турында бара. Кышкы агротехника чараларын тулысынча һәм дөрес итеп үткәрү ул, Кызыл Армиябезгә иң зур булышлыкларның берсе. Чөнки ул чараларны дөрес итеп һәм тулысынча тормышка ашыру турыдан-туры югары иген уңышы алуга хезмәт итә. Ә югары уңыш, димәк, икмәкне мул итеп җитештерү дошманны тизрәк җиңүгә ирешүдә төп шартларның берсе.

Кышкы агротехника чаралары планнары һәрбер колхозга күптән җиткерелде инде. Кар тотуга, җирле ашламалардан тирес, көл, кош тизәге, торф һәм башка ашламаларны туплауга бигрәк тә нык әһәмият бирергә кирәк. Кар тоту өчен куелган щитлар шул урында кар җитәрлек кадәр туплангач та, әлбәттә, икенче урыннарга күчерелергә һәм шул ук вакытта кар тоту буенча башка төрле методларны да киң күләмдә кулланырга кирәк. Колхозлардагы терлек абзарларыннан һәм колхозчы хуҗалыкларыннан чыккан тиресләрне һич тә әрәм итмичә җыеп барырга һәм тиресне басуга чыгарырга, анда аны яхшылап өеп барырга кирәк. Тиресне һәм көлне Кызыл юл районының Тукай исемендәге колхозындагы кебек кайда туры килсә, шунда түгеп әрәм итүләргә һич тә юл куярга ярамый. Андый фактлар, югары иген уңышы өчен көрәш эшенә тоткарлык ясау дип каралырга тиеш.

Кышкы агротехника чараларын үткәрү буенча һәрбер бригадага һәм һәрбер звенога конкрет заданиеләр җиткерергә һәм ул заданиеләрнең үтәлешен көн саен тикшереп торырга, шулай итеп заданиеләрнең үтәлүенә генә түгел, арттырып үтәлүенә ирешергә кирәк.

Җирле ашламаларның һәм кар тотуның югары иген уңышы алуга ирешүдә хәлиткеч чаралар булып исәпләнгәнлекләрен бер генә минутка да хәтердән чыгарырга ярамый. 1943 нче ел уңышы чыннан да хәрби уңыш булырга тиеш.

Соңгы сәгатьтә

11 нче январьда Төньяк Кавказда генерал-лейтенант И. И. МАСЛЕННИКОВ командалыгындагы безнең бер группа гаскәрләребез, каты сугышлардан соң ГЕОРГИЕВСК шәһәрен һәм тимер юл узелын, МИНЕРАЛЬНЫЕ ВОДЫ шәһәрен һәм тимер юл узелын, ПЯТИГОРСК шәһәрен һәм тимер юл станциясен, КИСЛОВОДСК шәһәрен һәм тимер юл станциясен, ЖЕЛЕЗНОВОДСК шәһәрен һәм тимер юл станциясен, БУДЕННОВСК шәһәрен һәм тимер юл станциясен, шулай ук район үзәкләре АЧИКУЛАКНЫ, АРХАНГЕЛЬСКОЕНЫ һәм АЛЕКСАНДРИЙСКАЯНЫ алдылар. Зур трофейлар кулга төшерелде, алар исәпкә алыналар.

Сугышларда генерал-майор В. А. ХОМЕНКО, генерал-майор К. А. КОРОТЕЕВ, генерал-майор П. М. КОЗЛОВ, генерал-майор К. И. МЕЛЬНИК гаскәрләре, генерал-лейтенант Н. Я. КИРИЧЕНКОНЫҢ һәм генерал-майор А. Г. СЕЛИВАНОВНЫҢ гвардия кавалерия берләшмәләре, шулай ук генерал-майор Г. П. ЛОБАНОВНЫҢ һәм подполковник В. И. ФИЛИППОВНЫҢ танк группалары сугышларда үзләрен аеруча күрсәттеләр.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Совет Информбюросыннан

10 нчы ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

10 нчы январьта каршы төндә безнең гаскәрләр Донның түбәнге агымы районында, Үзәк фронтта һәм Төньяк Кавказда элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең подразделениеләр штурм белән дошманның берничә ныгытмасын алдылар. Артиллеристлар пехотаның хәрәкәтләренә актив рәвештә ярдәм күрсәттеләр һәм дошманның ут точкаларын бастырдылар. Немецларның 20 ДЗОТ ы һәм блиндажы кулга төшерелде, 200 гә якын гитлерчы кырып ташланды. Сталинградтан төньяк-көнбатыштарак безнең артиллеристлар дошманның позицияләренә аттылар.

* * *

Донның түбәнге агымы районында совет гаскәрләре, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп һәм аның контратакаларын кире кайтарып, уңышлы рәвештә һөҗүмне дәвам иттерделәр. Бер участокта совет сугышчылары дошманның оборонасын өзделәр һәм, тар-мар ителгән дошманны куып барып, халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Сугыш кырында немец солдатларының һәм офицерларының 800 гә якын үле гәүдәләре, яндырылган 6 танк һәм җимерелгән 40 тан артык автомашина калды. 16 орудие, 47 пулемет, 20 миномет, 3 танкетка, 24 автомашина, бер радиостанция, сугыш припаслары, азык һәм башка хәрби материаллар саклана торган берничә склад кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең артиллерия уты белән гитлерчыларның контратакасы кире кайтарылды һәм немецларның 3 танкысы, бер самоход орудиесе, 7 автомашинасы һәм бер ротага якын пехотасы юк ителде.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр алган позицияләрендә ныгып урнаштылар һәм дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак немецлар контратакага зур пехота көчләре һәм күп санда танклар җибәрделәр. Бу участокта бик каты сугышлар 2 көн дәвам итте. Гитлерчыларның техникасы һәм җанлы көчләре гаять зур югалтуларга дучар ителде. Икенче бер участокта Н-че подразделениенең сугышчылары дошманның 130 солдатын плен алдылар.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр сугыша-сугыша алга бардылар һәм халык яши торган 30 пунктны алдылар. Күп санда трофейлар кулга төшерелде: 15 самолет, 22 танк, 30 орудие, 55 миномет, танкка каршы ата торган 260 мылтык, 241 автомат, 20 авиамотор, авиабомбалар саклана торган 2 зур склад, сугыш припаслары саклана торган складлар, шулай ук башка төрле бик күп хәрби милекләр. Иптәш Резниченко командалыгындагы частьның сугышчылары, чигенүче дошманны куып барып, 300 дән артык гитлерчыны юк иттеләр. Лейтенант Кузьменко подразделениесенең сугышчылары халык яши торган бер пунктка бәреп керделәр, берничә йортны алдылар һәм безнең башка подразделениеләребез бу пунктка килү юлларын һәм читләрен дошманнан тазартканга кадәр, немецларга өзлексез атып тордылар. Безнең подразделениеләрнең оста хәрәкәтләре нәтиҗәсендә бу пункт безнең яктан югалтусыз алынды. Гитлерчылар урамнарда 80 үле гәүдәләрен калдырдылар.

* * *

Төньяк Кавказда хәрәкәт итүче бер отрядның партизаннары дошманның бер транспорт самолетын юк иткәннәр һәм немецларның 2 очучысын үтергәннәр. Почта һәм документлар кулга төшерелгән. Шул ук отряд партизаннарының бер группасы шоссе юлындагы күперне яндырган һәм немецларның штаб машинасын юк иткән. Төньяк Кавказ партизаннарының икенче бер отряды дошманның фронт линиясенә бара торган тимер юл эшелонының һәлакәтен оештырган. Һәлакәт нәтиҗәсендә бер паровоз һәм 27 вагон ватылган. 100 дән артык гитлерчы үтерелгән һәм яраланган.

* * *

Сугышчыларның һәм командирларның бер группасы Төньяк Кавказда Котляревская тимер юл станциясе районында немец-фашист кабахәтләрнең ерткычлыклары турында акт төзегән. Актта болай диелә: «Котляревскаяда без бер склад бинасында 6 кызылармеецның һәм граждан киеме киенгән бер хатынның үле гәүдәләрен таптык. Гәүдәләрдә ерткычларча газаплауларның бик күп эзләре бар. Гитлерчылар үз корбаннарының күзләрен чукып чыгарганнар, бармакларын кисеп алганнар, аякларын каерып ташлаганнар, аларның битләре шул кадәр теткәләнгән ки, үлекләрнең кем икәнлекләрен танырга мөмкин түгел. Бары тик үтерелгәннәр арасында кызылармеец П. Н. Лещенконың булганлыгы гына билгеле булды. Ул разведкага барган вакытында яраланган һәм немецлар тарафыннан тотып алынган булган». Актка кул куйдылар: военфельдшер Петренко, өлкән лейтенант Белоглазов, старшина Молоховец һәм башкалар.

* * *

Хәбәрдар чыганаклардан алынган хәбәрләргә караганда, 1942 нче елның июненнән алып декабрьна кадәр, Германиянең төрле шәһәрләреннән Германия предприятиеләренә көчләп җибәрелгән ун меңнәрчә Бельгия эшчеләре үзләренең туган җирләренә качып киткәннәр.

„ТАТАРСТАН ХАЛЫК УКЫТУЧЫСЫ“ ИСЕМЛЕ САМОЛЕТЛАР ЭСКАДРИЛЬЯСЕ ТӨЗИК!

УКЫТУЧЫЛАРНЫҢ ПАТРИОТИК КҮТӘРЕЛЕШЕ

10 нчы январьда ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты һәм хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты укытучыларның шәһәр күләмендәге җыелышларын үткәрделәр. «Агымдагы момент һәм укытучыларның бурычлары» турында ТАССР Мәгариф эшләре халык комиссары иптәш Контюковның доклады тыңланды.

— Яшь буынны большевистик рухта, Ватаныбызга чиксез мәхәббәт, дошманга тирән нәфрәт хисендә тәрбияләргә.

— Балаларның яхшы һәм отличнo укуларына ирешергә, уку елының беренче яртысында булган өлгермәүчелекне бөтенләй бетерергә.

— Фронтовик балаларының укуларына һәм көн-күрешләренә игътибарны көчәйтергә.

— Сугышчыларга җылы киемнәр, бүләкләр җыю белән, сугышчан машиналар өчен средство туплау белән Кызыл Армиягә ярдәмне көчәйтергә һ. б.

Җыелыш резолюциясенә әнә шундый пунктлар язылды.

Ленин районы мәгариф бүлеге мөдире иптәш Попандополо барлык укытучыларның теләкләрен белдереп болай диде:

— Совет крестьяннары патриотик хәрәкәт башлап җибәрделәр. Колхозчылар танк колонналары, самолет эскадрильяләре төзүгә үзләренең хезмәт тиеннәреннән җыелган саклык акчаларын бирәләр. Бөтен илебезгә җәелгән бу хәрәкәттән совет укытучылары да читтә кала алмыйлар. Без, Ленин районы мәгариф бүлеге работниклары, «Татарстан халык укытучысы» исемле самолетлар эскадрильясе төзүгә средство туплый башларга тәкъдим итәбез һәм бу фондка беренче булып 3.000 сум акча кертәбез.

Җыелышка катнашучылар иптәш Попандополоның бу тәкъдимен алкышлап каршы алдылар.

— Туган Кызыл Армиябез өчен бернәрсә дә кызганыч түгел,—диде РСФСР ның атказанган укытучысы иптәш Григорьева,—мин самолетлар эскадрильясе төзелешенә 1 000 сум акчамны кертәм һәм барлык укытучыларны бу хәрәкәткә кушылырга чакырам.

39 нчы мәктәп директоры Краснова һәм 88 нче мәктәп директоры Карташова иптәшләр самолетлар төзүгә 1.000 әр сум, 11 нче мәктәп директоры Евдокимова, 25 нче мәктәптән Монастырева, 14 нче мәктәптән Николаев иптәшләр 500 әр сум, 2 нче класс укучысы Богомолкина 300 сум акча кертүләре турында белдерделәр.

Казан шәһәр укытучыларының гомуми җыелышы «Татарстан халык укытучысы» дигән самолетлар эскадрильясе төзелешенә акча җыярга чакырып, республикабызның барлык мәгариф работникларына мөрәҗәгать итте.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

10 нчы ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРУ

10 нчы январьда безнең гаскәрләр **Төньяк Кавказда,** һөҗүмне дәвам иттереп, **Воронцово-Александровское** шәһәрен, **Каменномостское** район үзәген, халык яши торган зур пунктлардан — **Сармаковоны, Камлюковны, Малканы, Петровскийны, Отказноены, Ново-Заведенскоены, Обильноены, Георгиевскаяны, Незлобнаяны, Лысогорскаяны** һәм тимер юл станциясе **Куманы** алдылар.

Донның түбәнге агымы районында һәм Үзәк фронтта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышларын дәвам иттерделәр.

3 нче январьдан 9 ына кадәр үткән атнада һава сугышларында һәм дошман аэродромнарында немецларның 313 самолеты юк ителде. Шул ук вакыт эчендә без 93 самолет югалттык.

Баренц дингезендә безнең корабльләр дошманның 12.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырдылар.

* * *

Сталинград районында безнең артиллерия уты белән, шулай ук штурм отрядларының хәрәкәтләре нәтиҗәсендә немецларның 300 гә якын солдат һәм офицерлары, 2 орудиеләре юк ителде, 27 ДЗОТлары һәм блиндажлары җимертелде. Совет разведчиклары 17 кешене плен алдылар. Пехота коралы уты белән немецларның 2 самолеты атып төшерелде.

* * *

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Күп кенә участокларда немецлар бик каты каршылык күрсәтәләр. Н-че часть алга таба барып, бер көн эчендә дошманның алты контратакасын кире кайтарды. Гитлерчылар зур югалтуларга дучар ителделәр, ләкин алар совет гаскәрләренең һөҗүм итеп баруын туктата алмадылар. Кичкә таба безнең подразделениеләр, кискен һөҗүм ясап, дошманның флангысына барып чыктылар һәм кинәт аның өстенә ташландылар. Ярты сәгать дәвам иткән бәрелештә немецлар тар-мар ителделәр. 600 дән артык гитлерчы һәм 8 немец танкысы юк ителде. 10 орудие, 27 пулемет, 12 миномет, 43 автомашина кулга төшерелде. Пленныйлар алынды. Зимовники районында совет гаскәрләре халык яши торган тагын берничә пунктны немец-фашист басып алучылардан азат иттеләр һәм дошманның бик күп җанлы көчләрен һәм техникасын кырдылар.

* * *

Үзәк фронтта элекке юнәлешләрдә сугышлар дәвам итте. Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак немецлар, танклар һәм бронемашиналар ярдәме белән, берничә тапкыр контратака ясадылар. Безнең подразделениеләр мылтык, пулемет һәм миномет уты белән дошман пехотасын танклардан һәм бронемашиналардан аердылар һәм аны юк итү өчен сугышлар алып бардылар. Икенче бер участокта командиры иптәш Маслов булган частьның артиллеристлары ут һөҗүме белән бер ротага якын немец пехотасын, дошманның 3 танкысын юк иттеләр һәм аның артиллерия утын бастырдылар.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр сугыша-сугыша алга бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че часть сугышчылары 200 дән артык гитлерчыны юк иттеләр һәм күп пленныйлар алдылар. Башка участокларда безнең гаскәрләр, дошманның туздырылган частьларын куып барып, бик күп трофейлар кулга төшерделәр. Алынган өстәмә саннар буенча, 20 танк, 170 автомашина, 180.000 снаряд, 25.000 кул гранатасы, 19.000 мина, танкка каршы ата торган мылтыклар өчен 141.000 патрон, 2 миллионга якын винтовка патроны, 5 миллион динамит һәм ракета патроннары, 400 ящик тол, 3 миллион данә артиллерия снарядлары гильзалары, 12.000 йомгак чәнечкеле тимер чыбык һәм күп кенә башка төрле сугыш милекләре кулга төшерелгән.

* * *

Ленинград фронтында безнең снайперлар ике көн эчендә 247 гитлерчыны кырдылар. Снайперлардан кече лейтенант иптәш Бродяной һәм кызылармеец иптәш Абраменко, дошман траншеяларыннан ерак түгел генә уңайлы ут позициясе алып, бер көн эчендә беренчесе 12 гитлерчыны һәм икенчесе 11 гитлерчыны юк иттеләр.

Ленинградка килү юлларында немецларның 2 самолеты атып төшерелде.

* * *

Латвия ССР ның бер районында хәрәкәт итүче отрядның бер группа партизаннары немецларның 3 хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Эшелоннарның берсе ике паровозлы булган. Вагоннар немец солдатлары һәм офицерлары белән шыгрым тулган булган. Һәлакәт вакытында вагоннарның күбесе җимерелгән. Берничә сәгатьтән немецлар һәлакәт булган урынга махсус санитария поезды җибәргәннәр. Санитария командасы авыр яраланган һәм үлгән гитлерчыларны бөтен көн буена диярлек җыеп йөргән. Латвия партизаннарының икенче бер отряды, юллардагы засадалардан торып, дошман солдатларыннан һәм офицерларыннан 44 кешене үтергән һәм 28 кеше яраланган.

* * *

Минскидагы концентрация лагереннан качкан Бобруйск шәһәре кешесе Андрей Сущевский болай диде: «Шәһәрдән 6 километр ераклыкта урнашкан Минск концентрация лагеренда 8 меңләп совет гражданнары һәм совет хәрби пленныйлар газап чигә. Гитлерчылар тоткыннарны кыралар, ләкин лагерь һәрвакыт өстәлеп тора. Анда немец хәрби властьларының приказларына саботаж ясауда шикләнелгән совет гражданнарын, Германиягә барудан баш тарткан ирләрне һәм хатын-кызларны, бик күп санлы һәм авыр налогларны түләмәгән крестьяннарны куып китерәләр. Ноябрь аенда лагерьга немец басып алучылар өчен эшләүдән кискен төстә баш тарткан 200 дән артык тимер юл эшчесен һәм хезмәткәрен куып китерделәр. Аларны беренче көнне үк бик каты кыйнадылар. Гитлерчылар машинист Аксючичны һәм диспетчер Володькины сукмырдылар. Укытучы Мациевичны гитлерчы палачлар декабрьда бик салкын көнне бөтенләй чишендереп өстенә су койдылар. Лагерьны саклаучы штурмовиклар һәркөнне дистәләрчә тоткыннарны үтерәләр. Шулай ук лагерьда ата-аналары белән бергә кулга алынган берничә йөз бала да бар. Күп балалар салкыннан һәм ачлыктан үләләр».

* * *

Берлиндагы бер авиация заводының аэродромында 17 нче декабрьда сынау вакытында 5 сугыш самолеты җимерелеп төшкән. Шул уңай белән самолетларның бик күбесендә зур кимчелекләр барлыгы беленгән. Бу заводта бик күп чит ил эшчеләре эшли.

Немецларның 306 нчы пехота дивизиясе составындагы 580 нче полкның 3 нче батальоныннан плен алынган лейтенант Гербер Юрс болай диде: «306 нчы дивизия Бельгиядә гарнизон хезмәте алып бара иде. 1942 нче елның 28 нче ноябрендә безне Брюссель—Дюссельдорф—Лейпциг—Львов—Шахты маршруты буйлап Көнчыгыш фронтка җибәрделәр. Шахты шәһәренә 580 нче һәм 581 нче полклар 10-12 нче декабрьда килеп җиттеләр һәм шуннан автомашиналарга төяп фронтка озатылдылар. Халык яши торган бер пунктта каты сугыш булды. Анда гитлерчылар бик күп артиллерия, 6 көпшәле миномётлар һәм 20 дән артык танк туплаганнар иде. Дошман уты астында безнең сугышчылар су чиге аркылы үтеп чыктылар һәм немецлар урнашкан урынга бәреп керделәр. Штык сугышы нәтиҗәсендә гитлерчылар алып ташландылар. Безнең гаскәрләр бик күп трофейлар кулга төшерделәр. Пленныйлар алынды.

* * *

Немец подразделениеләре Краснодар краенда хәрәкәт итүче бер партизан отрядын чолгап алырга маташканнар. Совет патриотлары бер тәүлек эчендә дошманны хәлсезләндергәннәр һәм засадалардан торып 100 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын кырганнар. Партизаннар, оста маневр ясап, чолганыштан чыкканнар. Краснодар партизаннарының икенче бер отряды бер тимер юл күперен шартлаткан һәм немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарган.

* * *

Немецларның 306 нчы пехота дивизиясе ... (see above)

без туздырылган һәм таркатылган частьларны алыштырдык һәм аларның позицияләренә урнаштык. Шул ук көнне руслар безгә атака ясап, безне чигенергә мәҗбүр иттеләр. Баштарак без оешкан төстә чигендек, ләкин соңыннан, чолганып алынудан куркып, яралыларны язмыш иркенә ташлап, качып киттек. Ләкин безне бу да коткармады. Рус танклары безнең чигенү юлларын кистеләр. Хәл өметсез иде һәм без пленга бирелдек».

* * *

Түбәндә Калинин өлкәсе, Балаболкино авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Балаболкино авылыннан чигенер алдыннан немец басып алучылар авыл халкын урамга куып чыгардылар һәм һәркемнең күз алдында 65 яшьлек Ефим Саратовны, 45 яшьлек Агафья Долгошеваны, 6 яшьлек Дмитрий Новиковны, 70 яшьлек Иван Климовны, 15 яшьлек Кузьма Солодковны, 75 яшьлек Терентий Росадны, 70 яшьлек Иван Платоновны, 72 яшьлек Дмитрий Солодковны һәм башка крестьяннарны атып үтерделәр. Берничә немец солдаты яшь колхозчы Евдокия Новикованы бер читкә өстерәп алып китеп, аны халык алдында мыскыл иттеләр, ә соңыннан автоматтан атып үтерделәр. Исән калган кешеләрне немецлар конвой астында авылдан куып алып киттеләр. Юлда еллар фашистлар пленлыгыннан качып котыла алдылар». Актка Балаболкино авылы кешеләреннән М. Курьяков, Е. Курьянова һәм М. Сидоровлар кул куйдылар.

11 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРУ

11 нче январьда безнең гаскәрләр **Төньяк Кавказда** һөҗүмне дәвам иттереп, **Георгиевск шәһәрен** һәм тимер юл узелын, **Минеральные Воды шәһәрен** һәм тимер юл узелын, **Пятигорск шәһәрен** һәм тимер юл станциясен, **Кисловодск** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, **Железноводск шәһәрен** һәм тимер юл станциясен, **Буденновск шәһәрен** һәм тимер юл станциясен, Карамык һәм Виноградная тимер юл станцияләрен, **Ачикулак, Архангельское, Александрийская** район үзәкләрен, халык яши торган зур пунктлардан **Горячеводскаяны, Свободаны, Ново-Григорьевскоены, Прасковеяны, Константиновсканы** алдылар.

Зимовники районында безнең гаскәрләр **Кутейниково** район үзәген, халык яши торган пунктлардан **Иловайскийны, Жирныйны; Русскийны; Ново-Лодинны** һәм тимер юл станциясе **Күберлене** алдылар.

Донның түбәнге агымы районында һәм **Үзәк фронтта** безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышларын дәвам иттерделәр.

Кара дингездә безнең корабльләр дошманның 4.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырдылар.

10 нчы январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 40 тан артык автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 6 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар, бер батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

Сталинградның заводлар районында безнең подразделениеләр дошманны күп кенә терәк пунктлардан бәреп чыгардылар һәм 6 урамны гитлерчылардан чистарттылар. Бу сугышларда 400 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Дошман бик нык каршылык күрсәтә һәм контратакаларга пехота һәм танклар җибәрә. Бер участокта безнең танклар частьте, алга таба барып, дошман оборонасының ныгытылган пунктларын алды. 5 танк, бер артиллерия батареясы, күп пулеметлар һәм автоматлар кулга төшерелде. Иптәш Репенко командалыгындагы хәрәкәттәге разведка отряды дошман тылына үтеп, немецларның пехота дивизиясе штабы урнашкан бер авылга бәреп керде. Разведчиклар 100 дошман солдатын һәм офицерын юк иттеләр, штабны туздырдылар, документлар кулга төшерделәр һәм үз частьларына исән-сау кайттылар.

* * *

Үзәк фронтта совет гаскәрләре үзләре алган позицияләрне ныгыттылар һәм дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Великие Лукидан төньяк-көнбатыштарак немецларның бер пехота полкы, 23 танк ярдәме белән, атакага күчте. Немецлар, зур югалтулар исәбенә, безнең подразделениеләрне бераз кысрыклый алдылар. Бу сугышта берничә йөз гитлерчы һәм 7 немец танкысы юк ителде. Күрше участокта немецлар иптәш Терехин командалыгындагы частьның позицияләренә каршы контратака ясадылар. Безнең сугышчылар, гитлерчыларның якынрак килгәнен көтеп торып, көчле ут белән немецларның 5 танкысын һәм ике ротага якын пехотасын юк иттеләр. Дошман элекке позицияләренә алып ташланды.

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр уңышлы рәвештә алга бардылар. Безнең моторлаштырылган һәм танк частьларыбыз Георгиевскины һәм Минеральные Воды-ны саклап тора торган дошман оборонасын өзеп, чигенүче немецларның артларыннан куып барып, бу шәһәрләргә барып керделәр һәм бик каты сугышлардан соң аларны алдылар. Безнең гаскәрләр Кисловодск, Пятигорск, Железноводск шәһәрләрен алдылар. Танклар, орудиеләр, күп төрле пехота коралларын, сугыш припаслары складлары, азык, запас частьлар һәм башка төрле хәрби милекләр тутырылган складлар кулга төшерелде. Н-че часть сугышчылары 500 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. 4 танк, 2 самоход орудие, 6 көпшәле 5 миномет, 17 пулемет һәм 2 сугыш припаслары склады кулга төшерелде. Гитлерчылар контратака ясап караганнар иде, ләкин миномет һәм мылтык-пулемет уты белән таркатылдылар.

* * *

Минск өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды 10 көн эчендә немецларның гаскәрләр һәм кышкы киемнәр төялгән 4 поездын юлдан чыгарган. 7 паровоз һәм 85 вагон җимерелгән. Сугышларда һәм поездлар һәлакәте нәтиҗәсендә 660 дошман солдаты һәм офицеры кырылган. Минск партизаннарының икенче бер отряды немецларның район үзәгендә урнашкан гарнизонына кинәт һөҗүм ясаган. Совет патриотлары 80 немец солдатын кырып ташлаганнар һәм бик күп трофейлар кулга төшергәннәр.

* * *

Түбәндә Ростов өлкәсенең Первомайск авыл советында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Без, түбәндә кул куючылар, бу актны шушы турыда төзедек: гитлерчы палачлар Первомайск авылында Маньково-Березовский, Усть-Мечетки һәм Россошь хуторларында торучы 40 кешене атып үтерделәр. Үтерелгәннәр арасында 16—17 яшьлек 6 яшь үсмер дә бар иде. Сычевка авылында немецлар Первомайск авыл советы депутаты Трашенконы, пленный командир Комиссаровны газапладылар һәм атып үтерделәр, соңыннан аларның гәүдәләрен чокырга ташладылар. Шуның өстенә фашист ерткычлар 6 пленный кызылармеецны аттылар. Кышкы салкында немецлар барлык колхозчыларны, балалары белән берлектә, йортларыннан урамга куып чыгардылар. Безгә үзебез белән азык та, кием дә алырга рөхсәт итмәделәр». Актка колхозчылардан И. Шелепов, И. Савченко, К. Поляков, П. Сушенко һәм П. Жуковлар кул куйды.

11 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРУ

11 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр **Донның түбәнге агымы районында, Үзәк фронтта** һәм **Төньяк Кавказда элекке** юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

Сталинградның заводлар поселогында безнең штурм группалары дошман оборонасының бер терәк пунктын алдылар. 300 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Сталинградтан төньяк-көнбатыштарак совет подразделениеләре 13 пулемет, 4 миномет, танкка каршы ата торган 7 мылтык, 26 винтовка һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр, дошманның контратакаларын кире кайтарып, һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть халык яши торган бер пунктны алды һәм трофейлар кулга төшерде. Шулар арасында зур сугыш припаслары склады, бер радиостанция һәм 18 автомашина бар. Немецлар контратака ясап карадылар, ләкин, пулемет утына очрап, сугыш кырында 100 дән артык үле гәүдәләрен калдырып, чигенделәр. Икенче бер участокта безнең танклар һәм моторлаштырылган пехотабыз, алга таба барып, дошманның ике батальонын тар-мар иттеләр. Немецларның 6 танкысы һәм 4 орудиесе юк ителде. Бер танк, 2 бронемашина һәм 11 йөк автомашинасы кулга төшерелде.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләрнең бер өлеше дошманның контратакаларын кире кайтарды. Н-че часть сугышчылары бик каты сугышта немецларның 9 танкысын яндырдылар һәм зарарладылар, 3 самоход орудиесен һәм бер ротадан артык пехотасын юк иттеләр. Икенче бер участокта дошман зур югалтулар исәбенә бер урында безнең позицияләргә үтеп керә алды. Безнең сугышчылар, бер-бер артлы контрударлар ясап, немецларны элекке позицияләренә алып ташладылар. Сугыш кырында дошманның 200 гә якын үле гәүдәләре, яндырылган 3 танкысы һәм гитлерчылар ташлап калдырган күп кораллар калды.

* * *

Төньяк Кавказда Н-че берләшмә частьлары уңышлы рәвештә алга бардылар һәм дошманны халык яши торган 13 пункттан бәреп чыгардылар. Н-че часть сугышчылары 250 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр, 6 орудие, 32 пулемет һәм бер радиостанция кулга төшерделәр. Бер су чиге якынында аеруча

КЫЗЫЛ АРМИЯГӘ ЯРДӘМНЕ ӨЗЛЕКСЕЗ ДӘВАМ ИТӘРГӘ!

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (Үзәк фронт). Рәсемдә: Н-че гвардия частеның иң яхшы автоматчигы, кызылармеец Павел Чиканов. Ул инде 100 дән артык гитлерчыны кырып ташлады. Күптән түгел СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. И. Калинин гвардеец Чикановка аның үз исеме язылган автомат тапшырды. ТАСС фотохроникасы.

Стахановчыларга СССР орденнары һәм медальләре тапшыру

СССР Верховный Советы Президиумы тапшыруы буенча, ТАССР Верховный Советы Президиумы председателе иптәш Динмөхәметов, баш инженеры иптәш Рукозенков булган заводның бүләкләнгән стахановчыларына, мастерларына, инженерларына, җитәкчеләренә орденнар һәм медальләр тапшырды. Бу мактаулы бүләкләрне тапшыру тантаналы шартларда үткәрелде. Эшчеләр клубы халык белән шыгрым тулы иде.

Сугышчан продукция эшләп чыгару буенча хөкүмәт заданиеләрен үрнәк төстә үтәгән өчен иптәш А. В. Саханицкийга «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены тапшырылды. А. М. Меркулов һәм Д. Д. Рукозенков иптәшләр «Кызыл Йолдыз» орденнары алдылар.

М. В. Бычков, Э. И. Пельц, К. Д. Черноусов, И. И. Шагаров, А. И. Усанова иптәшләр «Почет Билгесе» орденнары алдылар. Смена начальнигы Х. А. Гыйниятуллин, инженер О. В. Ступишина, стахановчылардан Н. Ф. Ефремова, В. Н. Панфутова, мастер А. П. Семин иптәшләргә «Хезмәттәге батырлык өчен» медальләре тапшырылды. Технолог А. П. Семенов, мастер Н. С. Четверкин, стахановчылардан Г. М. Калабин, П. Д. Савельев, А. Б. Иряшева, И. Е. Антонов һәм В. В. Геркен иптәшләр «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медальләре алдылар.

Бүләкләнүчеләр исеменнән Гыйниятуллин, Черноусов, Калабин һ. б. иптәшләр чыгып сөйләделәр.

— Хөкүмәтнең бөек бүләкләрен без үзебезнең стахановча хезмәтебез белән акларбыз,—диделәр алар барысы да.— Тагын да зуррак уңышларга ирешү өчен барлык көчебезне һәм белемебезне бирербез. Хезмәт фронтында без армый-талмый эшләрбез. Явыз дошманны тизрәк тармар итүдә Кызыл Армиягә ярдәмне көчәйтик!

Бүләкләнүчеләрне котлау сүзе белән ВКП(б) ның шәһәр комитеты секретаре иптәш Дельвин чыгыш ясады.

Орденнар һәм медальлар тапшыру тәмамлангач, иптәш Динмөхәметов речь белән чыкты һәм завод алдында торган төп бурычларга тукталып, коллективны 1943 нче елда тагын да бердәмрәк, ун тапкыр арттырылган энергия белән эшләргә, фронт һәм ил өчен продукцияне тагын да күбрәк бирергә чакырды. Бүләкләнүчеләрне чын күңелдән котлап, иптәш Динмөхәметов аларга производство эшендә алда яңа, зур уңышлар теләде.

УКЫТУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ЧИСТАЙ, 9 январь. (Телефон буенча). Шушы көннәрдә Чистайда укытучылар конференциясе булды. Анда 150 дән артык кеше катнашты. Укытучыларга халыкара хәл турында доклад куелды. Район мәгариф бүлеге мөдире иптәш Моратов уку елының ярты елы йомгаклары һәм алдагы бурычлар турында доклад ясады.

КЫЗЫЛ АРМИЯ ФОНДЫНА

АЗНАКАЙ, 11 январь. (Телефон буенча). Колхозчылар үз хуҗалыкларындагы запаслардан Кызыл Армия фондына ашлык тапшыруны дәвам иттерәләр. «Таллы бүләк» колхозы членнары 90 пот, «Сарсаз» колхозы членнары 50 пот, «Большевик» колхозы членнары 48 пот ашлык һәм танклар колоннасы төзү фондына 24.000 сум акча тапшырдылар.

«Зирекле елга» колхозы члены Мостәкыймов иптәш Сталинның телеграммасына җавап итеп, танклар төзүгә 7 мең сум акча бирде.

* * *

ЧҮПРӘЛЕ, 9 январь. (Телефон буенча). Иптәш Сталинның котлау телеграммасына җавап итеп, колхозчылар танклар колоннасы төзүгә акча бирү һәм Кызыл Армия фондына төрле продуктлар тапшыруны тагын да көчәйттеләр. Чапаев исемендәге колхоз председателе иптәш Смирнов танклар төзү фондына 10.000 сум акча тапшырды. Аннан үрнәк алып колхоз председателе урынбасары Емельянов, колхоз хисапчысы Бельдяков иптәшләр дә унар мең сум акча бүләк иттеләр. «Ялкын» колхозы члены иптәш Мөдәррисов танклар төзүгә 2.000 сум акча, Кызыл Армия фондына бер сарык бүләк итте.

Танклар төзү фондына район буенча 1 миллион 27 мең сум акча, Кызыл Армия фондына 138 центнер ашлык,59 сарык, 82 каз, 74 тавык һәм 65 килограмм май җыелды.

ИПТӘШ ДРОФИЛОВ 21.000 СУМ БИРДЕ

ЧИСТАЙ, 11 январь. (Телефон буенча). Районда колхозчыларның һәм колхозчы хатын-кызларның танклар һәм самолетлар төзүгә акча туплаулары дәвам итә. Бу патриотик хәрәкәт соңгы көннәрдә, республикабыз колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына иптәш Сталин тарафыннан җибәрелгән котлау телеграммасы алыну уңае белән тагын да көчәйде. Колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар бөек юлбашчының телеграммасына эш белән җавап бирергә ашкыналар.

Иптәш Сталинның телеграммасын уку өчен хәзерге көндә колхозларда җыелышлар, митинглар дәвам итә.

«Красный пролетарий» колхозы председателе иптәш Дрофилов танклар төзү фондына моннан элек 1.000 сум акча биргән иде инде. Иптәш Сталинның котлау телеграммасы аны тагын да рухландырды. Иптәш Дрофилов телеграмманы уку өчен җыелган митингта ук танклар төзү фондына тагын 20.000 сум акча бирде. Иптәш Дрофиловның 9 баласы бар, үзе инвалид. Ул колхоз эшләренә иң актив төстә җитәкчелек итә.

КОЛХОЗЧЫЛАР БҮЛӘГЕ

ШӨГЕР, 11 январь. (Телефон буенча). Ормышлы авыл советы (председателе иптәш Сәфәргалиева) танклар колоннасы төзү фондына 68.000 сум акча җыеп тапшырды. Иптәш Сталинның котлау телеграммасы уңае белән колхозчылар митингка җыелдылар. 3 улы Кызыл Армиядә булган Сафа иптәш Заһриев митингта болай диде:

— Иптәш Сталинның телеграммасы, аның безгә бу игътибары без колхозчыларны фронт өчен тагын да ныграк эшләргә, Кызыл Армиягә ярдәмне көчәйтергә рухландыра. Мин танклар колоннасы төзү өчен 1.000 сум акча биргән идем. Юлбашчының рәхмәтенә җавап итеп, Кызыл Армия фондына үз хуҗалыгымнан бер сарык бүләк итәм.

Иптәш Заһриевтан үрнәк алып шул митингта ук тагын 5 колхозчы Кызыл Армия фондына берәр сарык бирергә булдылар. Алар арасында Абдуллин, Хафизов, Идиятовлар бар. Колхозчы Сәйфуллин 32 килограмм ашлык бирде.

Әзерлек ярышы

ТЕЛӘЧЕ, 11 январь. (Телефон буенча). Иптәш Сталин телеграммасына җавап итеп, районның күп кенә колхозлары язгы чәчүгә әзерлек эшләрен шактый җәелдерделәр. «Биектау» һәм Вахитов исемендәге колхозларда әзерлек эшләре аеруча яхшы бара. Вахитов исемендәге колхоз 118 гектарда кар тоту үткәрде. Басуга тирес чыгару, көл һәм кош тизәге җыю да уңышлы алып барыла. Бу колхозлар бигрәк тә кар ятмый торган калку урыннарда кар тотуга әһәмият бирәләр. «Биектау» колхозында укучы балалар да җирле ашламалар әзерләүгә актив катнашалар.

«Кызыл Макса» колхозында барлык авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт тулысы белән тәмамланды. Хәзер бирдә чәчүлек орлыкларын чистарталар, анализга җибәрәләр.

«Красная Горка», «Кече Кибәхуҗа», «Красная звезда» һәм «Салкын чишмә» колхозлары барлык төр культуралар буенча үзләрен тәэмин итәрлек итеп чәчүлек орлыклары әзерләп куйдылар.

Н. МЕДВЕДЕВ.

Ашлык тапшыруга тоткарлык ясаучыларны каты җавапка

ЧИСТАЙ, 11 январь. (Телефон буенча). Чистай районында дәүләткә ашлык тапшыру эше һич тә канәгатьләнерлек бармый. Бүгенге көнгә план бары 30 процентка үтәлгән. Мәсәлән, Сталин исемендәге колхоз председателе Рыжов соңгы биш көндә бары 5 центнер ашлык тапшырган. Шул ук вакытта 80 центнер сугылган ашлыкны җибәрми тора. «Дружба» колхозы председателе Грачев соңгы биш көндә бары 33 центнер ашлык тапшырган. Ә шул ук вакытта 135 центнер сугылган ашлык амбарда ята. «Прогресс», «Кызыл юл» һәм Ворошилов исемендәге колхозлар исә 25 нче декабрьдан бирле дәүләткә бер килограмм да ашлык тапшырганнары юк.

Социалистик ярыш байрагын югары күтәрик!

Йөкләмәләр арттырып үтелә

Завком председателе урынбасары иптәш Батурин булган Н-че заводның коллективлары һәм аерым стахановчылары Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган ярышка кушылып алган йөкләмәләрен намус белән үтиләр.

Начальнигы Лизунов булган цехның мастер Бурлуцкий группасы стахановчылары заданиедән тыш 10 изделие өчен детальләр бирергә йөкләмә алганнар иде. Бу йөкләмәне алар һәркөн саен төгәл үтәп килә-ләр. Группада хезмәт җитештерүчәнлеге соңгы көннәрдә тагын да 25—50 процентка күтәрелде. Группаның бу гүзәл инициативасын бөтен цех күтәреп алды һәм планнан тыш детальләр тапшыру графигын цех һәркөнне арттырып үтәп килә.

Декабрь аенда планны 160 процентка үтәгән мастер Шемякин группасы коллективы хезмәт җитештерүчәнлеген бөтен группа күләмендә 200 процентка җиткерергә йөкләмә алган иде.Бу йөкләмә арттырып үтелә. Группа, 8 нче январьда заданиене 336 процентка, 10 нчы январьда—393 процентка үтәде.

Стахановчылардан Федоров, Галиуллин, Матвеев иптәшләр хезмәт җитештерүчәнлеген 25 процентка үтәргә йөкләмә алганнар иде. Менә дүртенче көн инде алар бу йөкләмәне ике тапкыр арттырып үтиләр.

Мастер Юсков группасы да зур уңышларга иреште. Бу группа декабрь аенда алдынгы урынга чыгып, цехның күчмә Кызыл Байрагын яулап алган иде. Группаның стахановчылары, Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган ярышка бердәм рәвештә кушылып, үз йөкләмәләрен арттырып үтиләр.

200.000 СУМЛЫК ӨСТӘМӘ ПРОДУКЦИЯ

13 нче номерлы лента-туку фабрикасының барлык цехларында Молотов исемендәге завод коллективының мөрәҗәгатен тикшерүгә багышланган митинглар булып үтте.

Митингларда чыгып сөйләүчеләр Кызыл Армиянең 25 еллыгын лаеклы каршылау өчен барысын да эшләргә, хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да күтәрергә, яхшы һәм отлично сыйфатлы гына продукция бирергә, һәрнәрсәгә экономия ясарга сүз бирделәр.

Фабрика коллективы барлык күрсәткечләр буенча планны арттырып үтәргә, Кызыл Армия көненә кадәр илебезгә 200.000 сумлык өстәмә продукция бирергә йөкләмә алды. Хәзер бу йөкләмәне үтәү өчен фабрика цехларында нык көрәш бара.

Мехчылар йөкләмәсе

ПЛАННАН ТЫШ БЕР МИЛЛИОН СУМЛЫК ПРОДУКЦИЯ

Кызыл Армиянең 25 еллыгына мехчылар коллективы производствода яңа җиңүләр яулап алу өчен эшлекле рәвештә әзерләнә. Комбинат фабрикаларының барлык цехларында да митинглар һәм җыелышлар үткәрелә. Аларда молотовчыларның мөрәҗәгате җанлы рәвештә тикшерелә. Коллективлар үз өсләренә яңа йөкләмәләр алалар. Мехкомбинат предприятиеләре данлыклы Кызыл Армиянең 25 еллыгына түбәндәгеләргә ирешү өчен көрәшәләр:

— 23 нче февральгә кадәр булган вакыт эчендә, планнан тыш бер миллион сумлык продукция эшләп чыгарырга.

— Мех полуфабрикатларга 10 процентан да ким булмаган күләмдә экономия ясарга.

— Планнан тыш 4.000 одеял эшләп чыгарырга.

— Кызыл Армия еллыгы көненә яңа төр продукция эшләп чыгаруны үзләштерергә.

Рузвельтның конгресска мөрәҗәгате

ВАШИНГТОН, 8 январь. (ТАСС). 7 нче январьда Америка конгрессының берләштерелгән сессиясендә президент Рузвельт түбәндәге речь белән чыкты:

«Конгрессның 78 нче сессиясе безнең илебез тарихының иң бөек моментларыннан берсендә җыелды. Үткән ел, ихтимал, хәзерге заман цивилизациясе өчен иң авыр ел булгандыр. Яңа кергән ел бик каты сугышлар белән үтәчәк. Ләкин шулай да ул күңелле вакыйгалар вәгъдә итә.

1942 нче елгы бөтен стратегия обстановкасында иң зур һәм иң әһәмиятле вакыйгалар—Россиянең гаять киң фронтларындагы вакыйгалар булды. Болар, беренчедән, Сталинградны бик нык саклау, ә икенчедән, төрле участокларда рус армияләренең ноябрьның икенче яртысында башланган һөҗүмнәре һәм аларның әле һаман да зур көч һәм нәтиҗә белән дәвам итүләре.

Үткән елның башка зур вакыйгалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: Филиппин атауларында, Голландия Һиндстанында, Малайяда һәм Бирмада японнарның күп кенә һөҗүмнәре, Тын океанның үзәк һәм көньяк өлешендә һәм Һинд океанында японнарның һөҗүме туктатылу, Мисырдан һәм Ливиядән ясалган һөҗүм нәтиҗәсендә Якын Көнчыгышта оборонаның уңышлы булуы, Америка һәм Англия кораллы көчләренең Төньяк Африканы алулары. Шулар артыннан, үзләренең әһәмиятләре ягыннан, 1942 нче елны пароходлар кәрваннары үтә торган юлларда туктаусыз барган бик каты сугышларны һәм авиация өлкәсендә өстенлекнең акрынлап күчәр державалары кулыннан берләшкән милләтләр кулына күчә баруын әйтеп үтәргә кирәк. Күчәр державалары үзләренең я 1942 нче елны сугышны отарга, яки, ахыр чиктә, бөтенесен югалтырга тиешлекләрен белделәр. Монда миңа безнең дошманнарыбызның хәзерге сугышны 1942 нче елны отып чыкмаганлыкларын әйтеп торуның кирәге юк».

Тын океанда сугышның барышына анализ ясап, Рузвельт болай диде:

«Без беләбез, Япониянең хәрби диңгез флотының һәм авиациясенең көче көннән-көн кими, ә шул ук вакытта Американың хәрби диңгез флотының һәм авиациясенең көче һаман арта бара. Көрәшнең соңгы нәтиҗәсен математика кебек дөрес итеп нигезләргә мөмкин. Без Япониянең үзенә удар ясагач һәм аны һавадан һәрвакыт бомбага тота башлагач бу нәрсә япон халкының үзе өчен дә ачык күренер. Япониягә каршы атакаларда безгә үзенең тынычлык идеаллары безнең идеалларга бик якын булган героик кытай халкы да кушылыр. Бу сугыш нәтиҗәсендә Кытай үзенә тынычлык, яхшы тормыш тәэмин итәр. Япония исә боларны рәхимсез рәвештә юк итәргә омтылган иде. Тын океанда дошманны хәлсезләндерү өчен без алып бара торган оборона сугышы чоры бетеп килә һәм хәзер безнең максатыбыз—японнарны сугышырга мәҗбүр итү. Үткән елны без аларны туктаткан идек, ә быел үзебез һөҗүм итәргә уйлыйбыз.

Үткән елны Европадагы сугыш мәйданында безнең иң беренче бурычыбыз, Германияне үзенең кешеләр һәм кораллар көченең бер өлешен сугышның икенче мәйданына күчерергә мәҗбүр итеп, рус фронтына ясала торган тупланган басымны йомшартудан гыйбарәт икәнлеге ачык иде. Күп айлар планлаштырып һәм бик җентекле әзерлекләр алып барганнан соң АКШ тан һәм Берләшкән Королевстводан Франция Төньяк Африкасына йөзләрчә корабльләр белән гаять күп, тупланган экспедиция җибәрелде. Ул тиешле урынга барып җитте, югалтулары бик күп булмады һәм инде бөтен хәрби обстановкага әһәмиятле йогынты ясады.

Россия, Кытай, Англия сугышчыларының һәм Британиянең дус милләтләренең барлык членнарының, хәзерге сугыш барган берничә ел буена безнең гомуми дошманнарыбызга каршы сугышкан һәм аларга дөньяны басып алырга мөмкинлек бирмәгән миллионнарча кешеләрнең тырышлыкларына Америка Кушма Штатлары тиешле бәяне бирәләр. Без үзләренең илләре күчәр урдалары тарафыннан басып алынган башка берләшкән милләтләрнең солдатларына, очучыларына һәм морякларына тиешле бәяне бирәбез. Союзникларның Төньяк Африканы оккупацияләүләре нәтиҗәсендә Франция армиясенең һәм флотының куәтле берләшмәләре, берләшкән илләрнең кораллы көчләре белән берлектә, хәрәкәткә керә башладылар. Без аларны союзниклар һәм дуслар дип карап котлыйбыз. Алар 1940 нчы елның июнь аендагы күңелсез көннәрдән башлап үзләренең җиңелгән илләрен азат итү өчен батырларча көрәшкән французлар белән бергә кушылалар.

Без үз союзникларыбызның җитәкчеләренә—Уинстон Черчилльгә, Иосиф Сталинга һәм генералиссимус Чан Кайшига тиешле бәяне бирәбез. Берләшкән милләтләрнең җитәкчеләре арасында бик реаль бердәмлек яшәп килә. Бу бердәмлек хәзерге сугышның киң стратегиясен планлаштыруда да, тормышка ашыруда да, шулай ук тәэмин итү линияләре төзүдә һәм аларны саклап калуда да күренә.

Мин күрәзәлек итә алмыйм. Мин сезгә берләшкән милләтләрнең Европада икенче ударны кайчан һәм кайда ясаячакларын әйтә алмыйм, ләкин без кыйнарга һәм нык кыйнарга җыенабыз. Без корыда ударны кайда һәм кайчан ясарбыз, шуңа да карамастан, без, англичаннар һәм руслар, дошманны һавадан кискен төстә һәм туктаусыз кыйнарбыз».

Производство фронтындагы йомгакларга һәм уңышларга күчеп, Рузвельт болай диде:

«1942 нче елга безнең самолетлар һәм танклар җитештерү программабыз сан ягыннан моннан бер ел элек билгеләнгән бурычка чагыштырганда үтәлеп җитмәде. Шулай булса да бездә үзебезнең 1942 нче елгы уңышлар белән мактанырга җитәрлек нигезләр бар. Без 48 мең чамасы сугыш самолеты эшләп чыгардык. Бу — Германиядә, Италиядә һәм Япониядә—шушы бөтен өч илдә булган авиация производствосыннан артып китә. Үткән елның декабрендә без 5.500 сугыш самолеты эшләп чыгардык һәм производство темпларын тизлек белән үсүдә дәвам итә».

Аннары Рузвельт АКШ ның кораллары үсүне күрсәтә торган мисалларны китереп үтә:

«Берничә ел тына әзерлек үткәргәннән соң һәм сугыш башлангач бер ел үтү белән үк без тоталь средстволар белән тоталь сугыш алып барырлык хәлдә булдык. Шуның белән бергә, без производстводагы уңышларыбызның руслар, англичаннар һәм кытайлар ирешкән уңышлардан зур булмаганлыгын искә алырга тиешбез. Алар үзләренең хәрби промышленностьларын сугыш тарафыннан тудырылган гаять авыр шартларда үстерделәр. Алар бомбага тотылу һәм караңгылык шартларында эшне дәвам иттерергә тиеш булдылар һәм бу эшне беркайчан да туктатмадылар.

Без, америкалылар, бу сугышта яхшы, батыр компаниядә торабыз һәм без үзебезнең мактаулы ролебезне гаять зур гомуми тырышлык белән үтибез».

Сүзендә дәвам итеп, Рузвельт болай диде:

«Без һәм барлык берләшкән илләр озакка сузыла торган гадел тынычлык телибез. Беренче бөтен дөнья сугышы белән икенче бөтен дөнья сугышы башлану арасындагы еллар эчендә без озакка сузылган гадел тынычлык шартларында яшәмәдек. Безнең кораллы көчләребезнең солдатлары озакка сузылган тынычлык булуны телиләр һәм алар шулай ук сугыш беткәннән соң үзләре өчен, үзләренең һәм күршеләренең семьялары өчен даими эш булуны телиләр.

Моннан ике ел элек мин үземнең ел саен җибәрә торган хатымда 4 азатлык турында әйткән идем. Бу азатлыкларның икесе—сүз азатлыгы һәм дин азатлыгы—безнең илебез тормышының әһәмиятле бер өлеше һәм, мин ышанам, бу ирекләр бөтен дөньядагы барлык халыкларга тәэмин ителер. Туган илләрендәге, шулай ук фронттагы кешеләр, ирләр һәм хатын-кызлар өченче азатлык белән—мохтаҗлыктан азат булу белән кызыксыналар. Димәк, алар өйләренә кайтканнан соң һәм сугыш производствосы тыныч рельсларга күчерелгәннән соң үзләре өчен һәм Америкадагы эшләргә теләүче һәм эшкә яраклы барлык ирләр һәм хатын-кызлар өчен эш алу хокукы алырга теләрләр. Мин моны конгресска шуның өчен әйтәм, чөнки бик ихтимал, мохтаҗлыктан азат булу турындагы—эш алуга һәм тормышта күздә тотылмаган очраклы хәлләрдән иминлек алуга хокук турындагы мәсьәлә—безнең алдыбызга үзенең бөтен күләме белән килеп басар һәм аны Америка якындагы 2 ел эчендә хәл итәргә тиеш булыр.

Без шуны истә тотарга тиешбез, Американың киләчәктәге экономик тынычлыгы, әгәр дә зур экономик сыклык дөньяның калган өлешенә дә җәелдерелмәсә, куркыныч астында булачак. Без Американы сугыш ягыннан да, экономик яктан да атаута әйләндерә алмыйбыз. Җинаятьнең яки һәлакәтнең нинди булса да башка формасы шикелле үк, гитлеризм да экономик һәм хәрби феодализмның явыз орлыкларыннан үсеп чыгарга мөмкин. Хәзерге сугышта отып чыгу—безнең алдыбызда тора торган беренче һәм иң бөек максат. Тынычлыкны отып алу—аннан соңгы максат. Бу, бездә һәм бөтен дөньяда кешенең тынычлыгын киңәйтү өчен—дүртенче азатлык өчен—куркып торудан азат булу өчен көрәш дигән сүз. Мин, әгәр дә бу сугыш ярым-йорты солых белән генә тәмам булса һәм хәзерге балалар армиягә алыну яшенә җиткәч яңа сугыш кабынып китсә, кешелек дөньясы һәм шул исәптән без, нинди хәлгә төшәрбез дип уйлап калтыранам. Безнең илебез бу сугышны уңайлы рәвештә тәмам итәр дип, ә соңыннан яңадан үз Америкасына кереп, аны бикләп куяр дип, һичшиксез, америкалыларның бик азлары гына уйлыйлар, Ләкин без беләбез, ерткыч хайваннардан сакларлык дәрәҗәдә шундый тирән чокырны беркайчан да казый алмаячакбыз. Шулай ук без, әгәр дә ерткыч хайваннарның атулы тешләрен йолкып алмасак, аларның үрчиячәкләрен, үзләренең көчләрен ныгытачакларын һәм иң якындагы буынның бугазына яңадан ябышачакларын беләбез.

Хәзерге вакытта берләшкән илләр тарихта иң куәтле хәрби коалиция булып торалар. Алар—бөтен дөньядагы халыкның иң зур күпчелеге. Үзләренең кайсы күршеләренә каршы булса да агрессия һәм басып алу актлары эшләмәячәкләре турында тантаналы килешү белән берләшкән бу илләр, Германиянең, Япониянең, Италиянең яки уныңчы бурычны бозарга маташучы кайсы булса да башка бер илнең яңадан коралланырга маташуын бетерү юлы белән тынычлыкны саклау юлында берләшкән хәлдә калулары мөмкин һәм калырга тиешләр».

Соңыннан Рузвельт болай диде:

«Мин бу сугышның кайчан бетәчәген алдан әйтә алмыйм. Ләкин мин уйлыйм, берләшкән илләр 1943 нче елны Берлинга, Римга һәм Токиога алып бара торган юлларда бик нык алга китәрләр. Безнең алдыбызда тыныч чорда да шулай ук сугыш чорында да үзенең әһәмияте һәм дәвамлылыгы ягыннан гаять зур бурыч тора. Ләкин озак дәвам итәчәк бу бурыч алдында без үз илебезнең яхшы хәлдә икәнлеген, милләтнең йөрәге таза икәнлекне, аның рухы көчле, ә дине нык икәнлекне истә тотарга тиешбез».

—*—

АНГЛИЯ АВИАЦИЯСЕНЕҢ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ ТУРЫНДА КРИППС

ЛОНДОН, 9 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, авиация промышленносте министры Стаффорд Криппс бер авиация заводында сөйләгән речендә болай дигән: «Германия һәм Италия тиздән һавадан тагын да катырак бомбага тотылуга дучар ителәчәкләр. Соңгы ике ай эчендә бомбага тотулар без теләгәнчә көчле булмады. Моңа һаваның начарлыгы сәбәп булды. Ләкин начар һава һәм томаннар сезоны үтеп бара, һәм без Германия һәм Италия өстенә яңадан бик күп санда бомбалар ташлый башлаячакбыз.

ВАН ЦЗИН-ВЕЙ АНГЛИЯГӘ ҺӘМ АКШ КА „СУГЫШ ИГЪЛАН“ ИТКӘН

ЛОНДОН, 10 январь. (ТАСС). Бирегә алынган хәбәрләргә караганда, Нанкинда булган Ван Цзин-вей «хөкүмәте» 9 нчы январьда Англиягә һәм Кушма Штатларга каршы сугыш игълан иткән. Бер үк вакытта сугышны алып баруда Япония белән Нанкин арасында хезмәттәшлек турында Токиода һәм Нанкинда декларация игълан ителгән.

ЛОНДОН, 9 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Кытайның Лондондагы рәсми даирәләре, Ван Цзин-вейнең курчак хөкүмәте тарафыннан Америка Кушма Штатларына һәм Британия империясенә сугыш игълан ителүе, Кытайда Чунцин хөкүмәтеннән башка тагын ниндидер бер хөкүмәт бар имеш дип тагын бер тапкыр иллюзия ясаудан башка берни дә түгел, дип саныйлар. Ван Цзин-вей һәм аның «хөкүмәте» Кытайның бер территориясендә дә аз гына авторитет белән дә файдаланмый.

Советлар Союзы Герое Марина Раскованың гробы янында

Советлар Союзы Герое Марина Раскованың гробы янына керту башлануга күп алда ук урамда мәрхүмә белән соңгы тапкыр күрешеп калырга килгән кешеләрдән озын чират тезелде.

Почетный каравылда мәрхүмәнең дуслары, сугышчан көрәштәшләре, бергә эшләгән иптәшләре. Шулар арасында авиация промышленносте наркомы Шахурин, ВЛКСМ Үзәк Комитеты секретаре Михайлов, ВЦСПС секретаре Николаева иптәшләр, авиация генерал-майоры Никитин, Осипенко, Соколоверов, инженер авиация хезмәте генерал-майорлары Степанов, Селезнев, Бибиков иптәшләр. Марина Раскованың бөтен дөньяга мәгълүм очышы үткәргән «Родина» самолеты эзләүдә катнашкан 1 нче ранг хәрби врач Тихонов, майор Полежай иптәшләр үзләренең сугышчан дуслары белән соңгы тапкыр күрешергә килгәннәр.

Командирлар, политработниклар, диңгез очучылары, кызылармеецлар, кызылфлотчылар, эшчеләр, хезмәткәрләр, укучылар, озын чират булып, гроб янына үтәләр.

21 сәгатьтә гроб янына керү туктатыла.

22 сәгатьтә Раскованың гәүдәсе кремациягә бирелә. (ТАСС).

СУГЫШ ИНВАЛИДЫ ИПТӘШ ЮНУСОВТАН ХАТ

Мин фронтка киткән вакытта Заинск районы Түбән Пәнәче авылында 6 кешедән торган семьям калды. Фронтта вакытта һәрвакыт мин алардан күңел рухландыра торган хатлар алып тордым. Алар үзләренең тормышлары яхшы булуын, бу турыда бер дә борчылмаска кушып язалар иде. Бу мине тагын да батырландыра, дошманны тагын да ныграк кыйнарга рухландыра иде. Чөнки фронтта вакытта сугышчы өчен бу гаять әһәмиятле нәрсә.

Әле күптән түгел мин, Сталинград фронтында яраланып, авылга кайттым. Кайткач мин семьямның тормышын үз күзем белән күрдем. Алар тиешле паек һәм пособиене вакытында алып килгәннәр. Кышка җитәрлек утын белән тәэмин ителгәннәр һәм аны өйгә ташып биргәннәр. Районда башка кызылармеец семьялары турында да яхшы кайгыртучанлык күрсәтелә. Бу эш белән район советы башкарма комитеты председателе Гыйлманов һәм секретаре Гыйззәтуллин иптәшләр турыдан-туры үзләре шөгыльләнәләр. Аларга һәм кызылармеец семьялары турында кайгыртучанлык күрсәтүче барлык кешеләргә рәхмәт әйтәсе килә.

Ш. ЮНУСОВ.

Җаваплы редактор урынбасары ГАЛИМ РЯБКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Зур драма театры. Бүген—„Тынычсыз картлык“.

Дәүләт циркы. Бүген чегән ансамбле катнашы белән зур цирк тамашасы. Кич 8 сәгатьтә башлана.

Татар дәүләт академия театры. Бүген премьера — „Мәрьям“. Беренче номер штамп сугылган билетлар белән керергә ярый.

„Электро“ — художестволы яңа фильм—„Сиңа сокландым“.

„Унион“—„Алтмыш тугызынчы параллель“.

„Пионер“ көндез — „Конек-Горбунок“, кич—„Волга-Волга“.

„Чатки“ — „Корыч ничек чыныкты“.

„Кызыл йолдыз“—„Гроза“.

Казан финанс-экономика институты СТУДЕНТЛАР КАБУЛ ИТӘ. Институт югары квалификацияле экономист-финансистлар әзерли. 1941—42 нче елларда урта мәктәпне тәмам итүчеләр 1 нче курска сынаусыз алыналар. Яңа алынган студентларның укуы 1 нче мартта башланачак. Урта мәктәпне тәмам итмәгән кешеләр өчен әзерлек курслары оештырылды. Адрес: Бутлеров урамы, 4 нче йорт, телефон № 73-34. 701-1

ПФ609 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 51